СОВЕТ
БОЛЬШЕКУРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ КАРАУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

**26.10.2023**

с.Большие Кургузи

**КАРАР**

**№ 143**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Карауҗа авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе турында" 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 12.11.20 № 12, 15.10.2021 №57, 29.05.2023 № 131 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 31.07.2023 № 389-ФЗ Федераль Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Олы Карауҗа авыл җирлеге:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү тәртибе турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы карарына (Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 12.11.2020 ел, № 12, 15.10.2021 ел, № 57, 29.05.2023 № 131 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 1.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1) торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән билгеләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып

алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3% шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш;»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.

3. Әлеге карарны 2023 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (СДК бинасы), Зур Күлбаш авылы, Подгорная урамы, 26 йорт (СДК бинасы).

Олы Карауҗа
авыл җирлеге башлыгы

Хөснетдинова Р. Ф.